КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 1 июль г.Казань № 526

Казан шәһәре һәм Зеденодольск муниципаль районы акваторияләрендә «SVIYAGA FEST – 2021» гаилә фестивален, шулай ук «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә су объектларыннан файдалану турында

Россия Федерациясе Су кодексының 6 һәм 25 статьялары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләрен раслау турында» 2009 ел, 23 апрель, 256 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан су объектларында кешеләр тормышын саклау кагыйдәләренең 1.3 пункты нигезендә, Казан шәһәре һәм Зеденодольск муниципаль районы акваторияләрендә «SVIYAGA FEST – 2021» гаилә фестивален, шулай ук «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәргәндә кешеләр тормышы иминлеген тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елның 10 июлендә 9 сәгать 00 минуттан 14 сәгать 30 минутка кадәр «SVIYAGA FEST – 2021» гаилә фестивален үткәрү чорында Свияга елгасы һәм Свияжск утрау-шәһәре тирәли яр буеннан 600 метр ераклыкта Идел елгасы участогында азсыешлы судноларны, шулай ук җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишкәкле көймәләрне кертеп) файдалануны тыярга.

2. 2021 елның 7 августында 12 сәгать 00 минуттан 20 сәгать 00 минутка кадәр «Мин күкне сайлыйм!» авиация бәйрәмен үткәрү чорында Казансу елгасы

участогында, Кремль дамбасыннан «Миллениум» күперенә кадәр, азсыешлы судноларны, шулай ук җилкәнле, ял итү, спорт судноларын (гидроциклларны, байдаркаларны, ишкәкле көймәләрне кертеп) файдалануны тыярга.

3. Бу карарның 1, 2 пунктларында күрсәтелгән судноларны файдалануны тыю «SVIYAGA FEST – 2021» гаилә фестивален, шулай ук «Мин күкне сайлыйм» авиация бәйрәмен әзерләүгә һәм үткәрүгә җәлеп ителгән судноларга кагылмый.

4. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына:

бу карарның 1, 2 пунктлары белән билгеләнгән тыюны үтәү максатларында әлеге участокларда көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итәргә;

халыкка кертелә торган тыю турында, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша мәгълүмат бирү эшен оештырырга.

5. Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча баш идарәсенә бу карарның 1, 2 пунктлары белән билгеләнгән тыюны үтәү максатларында көчләрнең һәм чараларның кизү торуын тәэмин итүне тәкъдим итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин